ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2023 г. Заинск № 35

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2020 елның 27 мартындагы 128 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында»**

«Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2022 елның 18 ноябрендәге 1234 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2020 елның 27 мартындагы 128 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

беренче пунктта «1 111» санын «2 510» санына алмаштырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Н. Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист
И.З. Әшрәпов
(85558) 2 80 44